ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

05 05 2023 г. № 100

Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының «Җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын яңа редакциядә раслау турында» 2021 елның 28 июнендәге 198 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Түбән Кама шәһәре Уставының 51 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының «Түбән Кама шәһәрендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен яңа редакциядә раслау турында» 2022 елның 28 мартындагы 69 номерлы карары нигезендә, Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының «Җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын яңа редакциядә раслау турында» 2021 елның 28 июнендәге 198 номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга кушымтада:

1 бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 1.6 пункт белән тулыландырырга:

«1.6. Алдан (проактив) режимда муниципаль хезмәт күрсәтү очраклары һәм тәртибе.

Муниципаль хезмәтләр алдан (проактив) режимда Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi. tatar.ru/) яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/) техник мөмкинлекне гамәлгә ашыру аша, гариза бирүче тарафыннан аңа әлеге муниципаль хезмәтне алдан (проактив) режимда күрсәтү турында соратуны алдан бирү шарты белән һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7.3 статьясындагы 1 өлеше нигезендә чаралар гамәлгә ашырылганнан соң күрсәтелә»;

2.3.2 пунктында «Учреждение» сүзен «Башкарма комитет» сүзе белән алыштырырга;

2.5.9 пунктының сигезенче абзацында «Учреждение» сүзен «Башкарма комитет» сүзе белән алыштырырга, «Учреждение җитәкчесе» сүзләрен «Башкарма комитетның вазыйфаи затлары» сүзләре белән алыштырырга;

2.10 пунктында «оешмалар тарафыннан бирелә торган» сүзләреннән соң «һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләт бирелгән экспертлар тарафыннан» сүзләре белән тулыландырырга;

3 бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 3.0 пункты белән тулыландырырга:

«3.0. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләренә күрсәтелгән, шул исәптән аны алу өчен алар мөрәҗәгать иткән уртак билгеләр белән берләшкән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләренә карата хезмәтләр күрсәтү тәртибен үз эченә алган муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүченең мөрәҗәгать итү ысулына бәйле рәвештә, 2.14 пунктында һәм әлеге бүлектә билгеләнгән.»;

3.1.1 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 6 пунктча белән тулыландырырга:

«6) техник хатаны төзәтү.»;

3.3.2.1 пунктның 10 абзацын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Формалаштырылган соратуны формат-логик тикшерү Бердәм портал тарафыннан мөрәҗәгать итүче соратуның электрон формасындагы һәр кырын тутыру процессында автомат рәвештә башкарыла. Бердәм портал тарафыннан дөрес тутырылмаган электрон формадагы сорату кыры ачыкланганда, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм турыдан-туры соратуның электрон формасында мәгълүмати хәбәр аша аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.»;

3.5.3 пунктында «Учреждение җитәкчесе тарафыннан» сүзләрен «Башкарма комитетның вазыйфаи заты тарафыннан» сүзләре белән алыштырырга, «Учреждение җитәкчесе» сүзләрен «Башкарма комитетның вазыйфаи заты» сүзләре белән алыштырырга;

3.6.2.2. пунктында «Учреждение» сүзен «Башкарма комитет» сүзе белән алыштырырга;

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны басма матбугатта һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче К.Р. Нәҗмиев

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044881